КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 27 март г.Казань № 176

2025 елга ачык өстенлекләр реестрын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан Татарстан Республикасының норматив хокук актларын эшләгәндә һәм гамәлгә ашырганда җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуны оештыру тәртибе турында» 2007 ел, 19 март, 90 нчы карарын тормышка ашыру максатларында, 2024 елда үткәрелгән социологик тикшеренүләр нәтиҗәләренә таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2025 елга ачык өстенлекләр реестрын (алга таба – Реестр) расларга.

2. Республика башкарма хакимият органнарына:

Реестрда күрсәтелгән ачык өстенлекләрне тормышка ашыру чараларын Татарстан Республикасының гамәлдәге һәм эшләнә торган дәүләт программаларына кертүне тәэмин итәргә, шулай ук боерык белән аларны тормышка ашыру мониторингын контрольдә тоту буенча җаваплы затларны билгеләргә;

2025 елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча, ачык өстенлектәге төп проблемалар исемлеге яктылыгында Реестрда күрсәтелгән ачык өстенлекләрне тормышка ашыру буенча башкарылган эш турындагы мәгълүматны «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә кертергә.

3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, башкарма хакимиятнең кызыксынучы республика органнары белән берлектә, массакүләм мәгълүмат чараларында республика башкарма хакимият органнарының Реестрда күрсәтелгән ачык өстенлекләрне тормышка ашыру буенча эш барышын һәм нәтиҗәләрен даими яктыртуны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елга ачык өстенлекләр реестрын раслау турында» 2024 ел, 25 март, 183 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары Р.К.Нигъмәтуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 27 март, 176 нчы карары белән расланды

2025 елга ачык өстенлекләр реестры

| Т/с | Өстенлекнең исеме | Өстенлекне билгеләгән халык өлеше, процент | Социологик тикшеренүләр нәтиҗәләре буенча төзелгән төп проблемалар исемлеге . |
|---|---|---|---|
| 1. | Бәяләр һәм тарифлар артуны тоткарлау | 60,2 | торак, азык-төлек продуктларының, бензинның, төзелеш материалларының, торак-коммуналь хезмәтләрнең шактый кыйммәтләнүе;<br>күпчелек сораштырылган халыкның гаилә бюджеты чыгымнарының гомуми күләмендә иң зур өлешне азык-төлек продуктларына чыгымнар тәшкил итә |
| 2. | Халыкның керемнәр (эш хаклары, пенсияләр, пособиеләр), халыкка социаль ярдәм күрсәтү дәрәҗәсен арттыру | 33,3 | ун процентка якын халыкның матди хәле аларга акчаларны азык-төлек продуктларына гына тотарга мөмкинлек бирә;<br>сораштырылган халыкның яртысыннан артыгының җыйган акчаларын саклау мөмкинлеге юк |
| 3. | Алкоголизмга һәм наркоманиягә каршы көрәш | 27,4 | халыкның күпчелек өлеше исерек хәлдә кылына торган җинаятьләргә борчыла;<br>алкогольне легаль булмаган сату һәм аның һәркем файдалана алырлык булуы;<br>наркотик чаралардан файдалану мөмкинлеге булу;<br>халкны сәламәт яшәү рәвеше алып баруга, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә игътибарын җәлеп итүгә игътибар җитмәү |

_______________